КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 август г.Казань № 1043

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Чистай шәһәре «Тарихи җирлекнең мәдәни-туристлык үсеше үзәген шәһәр структурасы фрагменты нигезендә төзү» ярдәмче проектын тормышка ашыру буенча төбәк эшче төркеме турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 17 июль, 593 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Чистай шәһәре «Тарихи җирлекнең мәдәни-туристлык үсеше үзәген шәһәр структурасы фрагменты нигезендә төзү» ярдәмче проектын тормышка ашыру буенча төбәк эшче төркеме турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 17 июль, 593 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 гыйнвар, 44 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай шәһәре «Тарихи җирлекнең мәдәни-туристлык үсеше үзәген шәһәр структурасы фрагменты нигезендә төзү» ярдәмче проектын тормышка ашыру буенча төбәк эшче төркеме турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацларында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта «кирәк булуга карап» сүзләреннән соң «, әмма кварталга кимендә

бер тапкыр» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 4.1[1] пункт өстәргә:

«4.1[1]. Эшче төркем түбәндәге составта төзелә: эшче төркем рәисе, эшче төркем рәисе урынбасары, эшче төркем әгъзалары һәм эшче төркем секретаре.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.2[1] пункт өстәргә:

«4.2[1]. Эшче төркем секретаре:

эшче төркем әгъзаларының эшче төркем утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен гомумиләштерә, эшче төркем утырышының көн тәртибен формалаштыра һәм аны эшче төркем җитәкчесенә, ә ул булмаган очракта яисә җитәкченең кушуы буенча эшче төркем җитәкчесе урынбасарына җибәрә;

эшче төркем утырышларына материаллар, шулай ук карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

эшче төркем әгъзаларына эшче төркем утырышының көн тәртибен җибәрүне гамәлгә ашыра;

эшче төркем әгъзаларын һәм чакырылган затларны барлык кирәкле белешмә-мәгълүмат бирү характерындагы материаллар белән тәэмин итә;

эшче төркем утырышы беркетмәсен алып бара.»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Чистай шәһәре «Тарихи җирлекнең мәдәни-туристлык үсеше үзәген шәһәр структурасы фрагменты нигезендә төзү» ярдәмче проектын тормышка ашыру буенча төбәк эшче төркеме составында:

эшче төркем составыннан Е.А.Бабичны, А.В.Печенкинны, Л.Р.Сафинны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Мансур улы Айзатуллинны;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Барисовна Борһанованы (килешү буенча);

«Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директорының экспозиция-күргәзмә эшләре буенча урынбасары Андрей Владимирович Еремеевны;

Фәрит Мөдәррис улы Хәнифовның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры»;

Ләйсән Гаптелхан кызы Низамованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, эшче төркем секретаре».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин